*Татарстан  Республикасы Нурлат шәһәре*

*13 нче номерлы “Талым” балалар бакчасы” мәктәпкәчә*

*белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

# *“Бәйрәмнәр бәйләме"*

Балалар бакчасында үткәрү өчен сценарийлар

җыентыгы

Җыентыкны төзеде:
Бикташева Ландыш Сәлихҗан кызы

Нурлат шәһәре
2025 ел

## Кереш өлеш

*Алтыннан бәһале, оҗмах нигъмәтләреннән*
*кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр.*
*Ата һәм ана өчен тәрбияле бала кебек*
*олуг байлык һич булмас.*
*Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык*
*һәм ахирәттә йөзгә аклык китерер.*
*Р. Фахретдин*

Без үз алдыбызга халык йолаларына, традицияләренә, иҗатына, гореф-гадәтләренә, сәнгатенә таянып балаларда туган телгә хөрмәт, халкыбызга карата гүзәл әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, милли фольклор әсәрләре аша, балаларның дөрес әдәби телдә сөйләшүләренә ирешү максатын куям.

Халыкның һәръяклап үскән шәхес тәрбияләргә омтылышын чагылдырган һәм шуңа ирешү юлында туган традицияләре бар. Гореф-гадәт, йолалар тормышны бер тәртипкә салу, аның аеруча мөһим булган бер вакыйгаларын мәгънәле, төпле, дөрес итеп кичерү, һәр нәрсәнең урынлы булуын аңлата. Кешегә шатлыклы һәм кайгылы мизгелләрдә югалып калмаска өйрәтә, ярдәм итә. Гасырлар аша буыннан буынга килгән бу кануннарның тирән тамырлары тәрбиягә барып тоташа.

Җыентыкка балалар иртәләрендә уздырыла торган төрле кичә һәм бәйрәмнәр тупланды.Алар яшь-буынга гореф-гадәтләрне саклауда ярдәи итәрләр дип уйлыйм.

## 1.“Тукай безнең күңелләрдә”

(уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә
Габдулла Тукай туган көненә багышланган бәйрәм.)

**Максат:** Балаларны татар халкының бөек шагыйре Г.Тукай турындагы белемнәрен киңәйтүне дәвам итү

**Бурычлар:**

1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга бөек шагыйрь Габдулла Тукайның тормыш юлын, шигырьләрен, әкиятләрен искә төшерү.

2. Иҗади сәләтләрен, сөйләм телен үстерү.

3. Шагыйрь иҗатына мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләүне дәвам итү.

**Җиһазлар**: интерактив такта, ноутбук, Тукай портреты, Тукай әсәрләренә иллюстрацияләр, урман күренеше өчен агачлар, куаклар, чәчәкләр, алтын тарак, капчык, рәсем һәм кул эшләре күргәзмәсе.

**Катнашучылар:** Кәҗә белән Сарык, Су анасы, Шүрәле

**Бәйрәм барышы:**

**Тәрбияче:** Бар күңелле лек дөньяда, бар бер ямь бүген, Нәрсәдәндер? Мин беләм! Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Апрель и Тукай не разделимы, ведь именно 26 апреля родился великий поэт татарского народа -Габдулла Тукай!

**1 бала** Илдә кояш, җирдә кояш,

Тукай көне канат җәйгән.

Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген,

Тукай көне – безнең бәйрәм!

**2 бала** Ямьле язлар белән бергә

Дөньяга килгән Тукай.

Ул һаман да безнең белән,

Ул һаман да яшь бугай.

**3 бала** Мысли о Тукае не дают покоя

Как не справедлива с ним была судьба!
Маленького Тукая по земле гоняя,

Гения народного потерять могла.

**4 бала** Горестей немало видел Габдулла,

Оттого добрейшей была его душа.

Только всё прекрасное он в сердце пускал,

Ну, а злобу, ненависть напрочь отгонял.

***“Бәйрәм бүген” җыры***

1. Бар күңеллелек бөтен дөньяда,

Бар бер ямь бүген!

Нәрсәдән бу? Мин беләм:

Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген.

2. Яр башында тыңладым мин

Бер суның дулкыннарын.

Сөйләшәләр үзара: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген.

3. Арттыра, күрдем, кояш, гадәттәгедән балкуын

Ул киенгәндер дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген.

**Воспитатель:** Габдулла Тукай написал для детей много стихов, песен, сказок и загадок. Он очень любил свой родной язык, воспевал его красоту. Каждый год в день рождения поэта у памятника в Казани собираются любители поэзии, поэты Татарстана.

Иң матур җир кайда? - дисез,

Билгеле: Кырлай җире.

Барча әкият геройлары

Кырлайда туган инде.

Су анасы, Шүрәлеләр

Ел да җыела бире.

Җыелмас иде, Кырлай шул

Аларның туган җире.

В центре сцены сидит Водяная и с золотым гребнем расчёсывает свои длинные волосы, напевает. Затем откладывает в сторону гребень, встаёт, рассматривает себя в зеркале. В это время появляется какой - то мальчик, незаметно подкрадывается и крадёт гребень. Когда Водяная его замечает, он уже оказывается далеко. С другой стороны сцены выходят наши герои.

**Водяная:** Украли, украли! А-а-а! (плачет).

**Ребёнок:** Здравствуйте! Что у вас украли?

**Водяная:** Мой гребень, мой золотой гребень… Чем я теперь волосы буду расчесывать?!

**Ребёнок:** Тётушка Водяная, пожалуйста, не горюй, не плачь. Ведь сегодня праздник.

**Водяная:** А какой праздник?

**Ребёнок:** Сегодня день рождения великого поэта и писателя – Габдуллы Тукая. Он и для детей написал много интересных стихотворений и сказок. В честь него у нас в садике будет развлечение. Тётушка Водяная, пойдём с нами!

**Водяная:** Нет, нет, что Вы. Я боюсь.

**Ребёнок:** Пойдём, пойдём с нами. Мы тебе новый гребень подарим. ещё лучше прежнего.

**Водяная:** Ну хорошо. (ребёнок ведут водяную на праздник.

**(Су анасы начинает искать свой гребень).**

**Воспитатель:** Ребята, посмотрите, к нам Су анасы пришла. А что ты ищешь?

**Водяная:** Один мальчик украл мой золотой гребень . Чем я теперь волосы буду расчесывать?! Может быть этот мальчик среди вас спрятался? Покажите мне этого воришку!

**Воспитатель:** Успокойся, Водяная. Среди наших детей нет таких мальчиков.

Наши дети очень воспитанные, умные, и чужые вещи не трогают.

А ещё они любят петь, танцевать и в разные игры играть. Водяная, а ты с нами поиграть не хочешь?

**Водяная:** Хочу.

***Хороводная игра “Су анасы”***

Су анасы, су анасы,

Су анасын күр әле.

Каршыңда кем басып тора,

Ялгышмыйча әйт әле.

Балалар түгәрәккә басалар, Су анасы уртада кала. Аның күзләрен яулык белән бәйлиләр. Балалар җырлый-җырлый әйләнәләр. Җыр туктауга Су анасы бармагы белән кемгә төртеп күрсәтә, шуны танырга тиеш була.

**Воспитатель:** Су анасы, мы тебе дарим новый гребень. Будь внимательнее, больше не теряй.

**Водяная:** Спасибо большое.

*Выходят Коза и Баран. У них в руках пустой мешок. Сами очень грустные. Садятся и тяжело вздыхают.*

**Воспитатель:** Здравствуйте, тётушка Коза и дядюшка баран. Почему вы такие грустные?

**Баран и Коза:** Наши хозяева – бабушка и дедушка – сказали, что они уже стали очень старые, и больше не могут ухаживать за нами, и кормить нас. Поэтому попросили нас уйти. А куда мы пойдём? В лес? Там ведь волки. А вдруг они нас съедят?! Что же нам теперь делать?! Ах, бедные мы, бедные.

**Воспитатель:** Не переживайте вы так. Что-нибудь придумаем.

А знаете что? Мы вас приглашаем на праздник. Сегодня у нас в садике развлечение. Будем петь, и танцевать, играть и веселиться!

**Коза и Баран:** Исәнмесез балалар. Узнали нас?

**Дети: Исәнмесез.** Әйе.

**Коза и Баран:** Ну, из какой же сказки мы?

**Дети:** Из сказки Коза и Баран – Кәҗә белән Сарык.

**Воспитатель: Давайте вместе отпразднуем день рождения Габдуллы Тукая.**

**Коза и Баран:** Бүгенге бәйрәмегезгә,

Буш кул белән килмәдек.

Сезгә бер кызыклы

Уен алып килдек.

***Уен "Түбәтәйле"***

Сарык белән Кәҗә балаларга татар халкының "Түбәтәйле" уенын уйнаталар. Балалар түгәрәккә басалар. Бер балага түбәтәй кидерәләр. Татарча бию көе яңгырый. Балалар түбәтәйне чират буенча бер-берсенең башына кидерәләр. Көй туктаганда түбәтәй кемдә кала, шул бала Г.Тукайның шигырен сөйләргә тиеш була.

В музыкальный зал заходит хмурый,обиженный Шурале.

**Шурале:** Все собрались на праздник,один я в лесу остался. Что вы тут на этот раз отмечаете?

**Воспитатель:** Сегодня день рождения татарского поэта – Габдуллы Тукая. И в нашем детском саду праздник, посвященный дню его рождения. Шурале мы и тебя приглашаем на этот праздник.

**Шурале:** (задумывается) Габдуллааа Тукай - это ведь тот писатель, который сочинил меня. Да, конечно же пойду. (Шурале среди детей)

***Уен " Куш кулым "***

*(Шурале подходит к детям и пытается их пощекотать)*

– Давайте поиграем в щекотки.

**Воспитатель:** Шурале, а ты кроме щекотки ещё что- нибудь знаешь? (нет) А наши ребята знают. Мы приглашаем тебя посмотреть сказку.

«Эш беткәч уйнарга ярый»

**Шүрәле:** Ой спасибо. Я больше людей не буду щекотать, лучше буду сними играть и песни петь. Ребята, а сейчас с вами поиграем с бубном**.**

**Водяная :** Мне тоже понравилась у Вас на празднике.

**Сарык белән Кәҗә:** Нам было с вами весело и интересно.

**Воспитатель:** Дорогие дети, гости, воспитатели, артисты давайте вместе с Вами споем песню "Туган тел"

***Жыр "Туган тел"***

Дети прощаются с героями.

**Воспитатель:** Вот и подошел наш праздник к концу. На этом мы с вами прощаемся.

**2."Кызыл ромашка таҗлары"**

**Патриот шагыйрь - Муса Җәлилгә багышланган кичә**

**Виктория :** Юллар,юллар! Мине туган йорттан

Аерып ерак алып киттегез.

Җитәр инде, озак кунак булдым,

Хәзер кире өйгә илтегез...

*(слайд юллар, М.Җәлил портреты)*

**Алып баручы:** 1906нчы елның 15нче февралендә Оренбург губерниясе Мостафа авылында Муса Җәлил дөньяга килә.

Гаиләдә ул алтынчы бала бала була. Әтисе- Мостафа Җәлилов, әнисе – Рәхимә Җәлилова. Башка балалар кебек ул да яланаяк яшел чирәм өстендә йөгергән, казлар көткән, су коенган, әнисенең моңлы җырларын тыңлаган.

*(слайд Муса гаиләсе белән)*

**А.б.** Шигырьләр язу дәрте Мусада иртә уяна. Туганнан туган апасы Мәрьям Сәйфетдинова искә төшергәнчә, 1915 елларда Муса Г.Тукай кебек бөек шагыйрь буласы килүен әйтә.

Бик күп сикәлтәле юллар үтеп, Муса белем ала һәм халыкны мәдәниятккә алып чыга. Ул шигырьләр, поэмалар, либретталар иҗат итә. Бер-бер артлы аның китап басмалары чыга, бигрәк тә, балалар өчен.

***Чулпан Мунировна Муса Җәлилнең“Сәгать”шигырен укый***

**А.б.** Ләкин шагыйрьнең иҗади эшчәнлеге чынга ашмый кала. Бөек Ватан сугышы башлана....

**Рината:** Сау булыгыз, дуслар,- диде Муса

Әкрен генә поезд кузгалды

Калды Казан, киттең син сугышка

Ерак иде солдат юллары.

*(слайд Муса хәрби киемнән)*

**А.б.** Сугышның беренче көннәреннән үк Муса фашистларга каршы корал һәм каләм белән көрәшен башлый. Аның сугыш тематикасына багышланган

**“** Дошманга каршы”, “Артиллерист анты” җыентыкларында җырлар, патриотик шигырьләр туплана. Шагыйрьнең һәрбер шигырендә Туган илгә, Ватанга мәхәббәт, якыннарга карата җылы хисләр чагыла.

1942 елның июлендә авыр яраланган Муса фашистларга әсирлеккә эләгә. Бу хәл Волхов фронтында була.

(слайд Волхов фронтындагы сугыш кадрлары)

**А.б.** Фашист төрмәсе .... Ачлык,ләкин монда да М.Җәлил коралын кулыннан төшерми . Ул фашистларга каршы үзенең сыналган коралы-каләме белән көрәшүен дәвам итә.Үзенең якташларын табып, чын дуслар белән көрәшен дәвам итә.

“Без үлемнән көчлерәк булырга тиеш,” – дип Муса үзенең көрштәшләренә берничә тапкыр кабатлый. Бердәмлек, дуслык җәлилчеләргә көч һәм дәрт өсти.

Ләкин фашистлар бу группаны тар-мар итәләр. Җәлилне һәм җәлилчеләрне Герман концлагеренә озаталар.

*(слайд Плетцензее һәм Моабит төрмәләре)*

**А.б.** Әсирләрне аерым камераларга ябалар, кулларын, аякларын бәйлиләр. Фашистлар шагырьне кыйныйлар, кулын сындыралар... Сынган, шешкән бармаклары белән Муса шигырьләр язуын дәвам итә.

Моабит төрмәсендә Җәлил якын дустын , балалар язучысын, Абдулла Алишны очрата.

*(слайд А.Алиш портреты)*

**А.б.** Җиңел булмый шагыйрьгә, ул гаиләсен сагына, кечкенә кызчыгы Чулпанны һәм хатыны Әминәне.

***Гузель Газинуровна Муса Җәлилнең тормыш иптәше Әминә,кызы Чулпан белән төшкән фотосүрәтен күрсәтә***

***(слайд Муса кызы Чулпан белән)***

**Тимур:** Ромашкалар, ромашкалар

Күңелләрдә күпме алар?

Бухенвальдта, Моабитта

Шпандауда- ромашкалар.

*(слайд ромашкалар аланы)*

Муса Җәлилнең“Кызыл ромашка” шигыренә инсценировка

А.б. 1944нче елның 25 августы , иртәнге тынычлыкны солдат аяк тавышлары боза. Акрын гына ишек ачыла.

Камерага фашистлар керә. Алар татарларның исемлеген укып, тиз генә чыгарга кушалар.

Әсирләр аңлыйлар, бу аларның соңгы сулышы...

Тыныч баралар. Шул вакыт Муса җырлап җибәрә...

***Лариса Владимировна Муса Җәлил сүзләренә язылган***

***“Теләр идем” җырын башкара***

**Бу** уйламаганда килеп чыга. “Молчать” дип кычкыра конвой.

Ләкин татарлар кулларын кысып, башларын күтәреп, җырны тагын да көчлерәк рух белән дәвам итәләр. Алар бер-берсенә елмаялар иде.

1944нче елның 25нче августы 12 сәгать 06 минут, фашистлар чакыра башлыйлар.

А.б. Беренче булып Гайнан Кормаш.

Берсе артыннан берсе ,  һәр 3 минут саен, татарлар китteләр...

12 сәгать 9 минут.

Фоат Сәйфелмөлеков.

12 сәгать 12 минут.

Абдулла Алиш.

12 сәгать 15 минут.

Фоат Булатов.

12 сәгать 18 минут.

Муса Җәлил.

12 сәгать 21 минут.

Гариф Шабаев.

12 сәгать 24 минут.

Әхмәт Симаев.

12 сәгать 27 минут.

Абдулла Батталов.

12 сәгать 30 минут.

Зиннәт Хәсәнов.

12 сәгать 33 минут.

Әхәт Әтнәшев.

12 сәгать 36 минут.

Сәлим Бохаров.

**А.б.** Татар халкының бөек улларын юк итәр өчен, фашистларга бары 30 минут вакыт җитә.

Туган илнең батыр улларын искә алып, бер минут тынлык игълан ителә.

***(Бер минут тынлык)***

**А.б.** Шагыйрь үлмәде! Аның Туган илгә ике китапчыгы кайта, бу шагыйрьнең төрле илләргә таныш булган “Моабит дәфтәрләре”. Кызганычка каршы, өченче дәфтәре табылмады.

(слайд “Моабит дәфтәрләре”)

***Рузалия Рашитовна Муса Җәлилнең “Карак песи” шигырен укый***

**Радэль:**

Килер ул көн, халык хөкем итәр,

Карар булыр кискен һәм кыска.

Каным белән язган соңгы җырым,

Бул гаепләү акты фашистка.

*(слайд М.Җәлил һәйкәле)*

***Самигулова Рината Муса Җәлилнен "Платочек"шигырен сөйли***

**А.б.** 1956нчы елны Муса Мостафа улы Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелде. 1957нче елны "Моабит дәфтәрләре" өчен Җәлил Ленин пермиясенә лаек булды.

**Рәсил:**

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас

Ялкынлы җыр тулы күңелне,

"Үлем" диеп әйтеп буламы соң

Җиңеп үлгән мондый үлемне?

**А.б.** 1944нче елның 25нче августы Муса Җәлил Берлинның төрмәсендә хөкем ителә. Ләкин аның җырлары Туган илгә әйләнеп кайта.

**Доминик:**

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә

Һәм үләргә кыю ир булып.

**Бергә:**

Гомрем минем моңлы бер җыр иде,

Үлемем дә яңрар җыр булып.

**Балалар** "Дружат дети всей земли» җырын башкаралар.

Шире круг, шире круг, музыка зовёт

Всех друзей, всех подруг в шумный хоровод!

Шире круг, шире круг, музыка зовёт
Всех друзей, всех подруг в шумный хоровод!

Дружат пчёлка и цветок, дружат лист и мотылёк,
Дружат реки и леса, дружат в хоре голоса

Пр-в: Шире круг, шире круг, музыка зовёт
Всех друзей, всех подруг в шумный хоровод!
Шире круг, шире круг, музыка зовёт
Всех друзей, всех подруг в шумный хоровод!

Дружат птицы в вышине, дружат рыбы в глубине,
Дружит с небом океан, дружат люди разных стран
Пр-в: Шире круг, шире круг, музыка зовёт
Всех друзей, всех подруг в шумный хоровод!
Шире круг, шире круг, музыка зовёт
Всех друзей, всех подруг в шумный хоровод!
Дружат солнце и весна, дружат звёзды и луна.
Дружат в море корабли, дружат дети всей земли!
Пр-в: Шире круг, шире круг, музыка зовёт
Всех друзей, всех подруг в шумный хоровод!
Шире круг, шире круг, музыка зовёт
Всех друзей, всех подруг в шумный хоровод!

**3. “Сөмбелә” бәйрәме.**

**Максат:** балаларны татар халык бәйрәмнәренең берсе - Сөмбелә бәйрәме белән таныштыру.

**Бурычлар:**

1.Балаларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү.

2.Балаларның игътибарын, үзләштерү, кабул итүне, сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү.

3.Татар халык бәйрәмнәренә кызыксыну уяту һәм татар халкына мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** зал бәйрәмчә көзге яфраклар, татар орнаментлары белән бизәлгән, кәрзиндә яшелчәләр тутырылган, уен өчен капчыкта бәрәңге.

Әзерлек эшләре: шигырьләр ятлау, җырларны өйрәнү.

С.Сәйдәшевның “Уңыш вальсы”на балалар залга керә.

**Алып баручы**: Балалар, хөрмәтле кунаклар! Бүген без халкыбызның иң гүзәл бәйрәмнәренең берсе – "Сөмбелә" бәйрәменә җыелдык. Елның сихри фасылында, көн белән төн тигезләшкән мәлдә, татар халкы Сөмбелә бәйрәмен үткәргән. Ул – көзге бәйрәм, уңыш бәйрәме

Көз килде,

Уңыш булды,

Табын сый белән тулды.

Рәхим итегез, дуслар,

Көзге бәйрәмгә!

Ашлык булып җирдә үсә

Уңыш бит ул, Сөмбелә! **Рината**

Бөтен җирне нурга күмә

Кояш кебек Сөмбелә.

***Җыр “Көз”***

**Алып баручы:** Балалар, инде бәйрәмебезгә Сөмбеләне чакырыйк.

(Матур көйгә Сөмбелә керә)

**Сөмбелә:** Саумы, якын дусларым!

Сезне сагынып килдем мин.

Сезгә аяз көннәр дә,

Байлык та китердем мин.

Мин – көз кызы – Сөмбелә,

Көзге байлык кулымда.

Чакырам мин һәммәгезне

Шушы бәйрәм түренә.

**Алып баручы:** Балалар, әйдәгез сорыйк әле, Сөмбелә безгә нәрсәләр алып килде икән?

(Балалар җитәкләшеп, түгәрәк ясыйлар, “Көз, көз, әйт әле” җыры башкарыла).

**Сөмбелә:** Балалар, әйдәгез, табышмак уены уйнап алабыз.

Кырлар буш кала , яңгырлар ява,

Җирләр дымлана, бу кайчак була? (көз)

Яз килсә − киенә,

Көз килсә − чишенә. (агач)

Ура-суга , җилгәрә,

Үзе төяп җибәрә.

Бик күп эшләп игенне

Баета ул илемне. (комбайн)

Үзем туныйм, үзем елыйм да елыйм. (суган)

Тәрәзәсе юк, ишеге юк,

Эче тулы халык.(кыяр)

”Алма” дисәң дә алалар

Нәрсә соң ул балалар? (алма)

Йодрык- йодрык  булып төшә.

Алма кебек кызарып пешә.

Үзе бик матур, аны кем әйтер? (помидор)

**Сөмбелә:**   Табышмаклар күп беләсез,

Зирәк икән  үзегез.

Бәхетле һәм матур булсын

Сезнең һәрбер көнегез.

**Алып баручы:**  Дуслар, бәйрәмгә килгәнсез,

Гөлдәй матур киенгәнсез.

Ниләр китердегез көзгә,

Сөйләп бирегезче безгә!

Яшелчәләр булып киенгән балаларның чыгышлары тыңланыла.

Кәбестә

Мин булам - кәбестә

Үзем гел яшькелт төстә.   **Рәсил**

Күлмәгем күп катлы,

Үзем мин бик татлы.

Суган:

Минем исемем – суган

Мин Һиндстанда туган.

Мине бик тә мактыйлар **Доминик**

Шифалы дип атыйлар.

Бәрәңге

Тыгызланып,туп кебек

Үсеп җитә бәрәңге. **Радэль**

Кырда,көлдә пешкәне

һай,бигрәк тәмле инде.

**Алып баручы:** Бәйрәм мөбарәк булсын,

Табыннар түгәрәк булсын!

Барыбызга да сәламәтлек,

Тыныч көннәр насыйп булсын!

Балалар, без бик күп яшелчәләр үстерәбез, тәмле – тәмле ризыклар пешерәбез. Ә иң кирәкле, иң тәмле ризык нәрсә ул? (Балалар: икмәк)

**Сөмбелә:** Дөрес, балалар. Иң тәмле, иң кирәкле ризык ул – икмәк.

**Алып баручы:** Ипи басуда үсә

Аннан амбарга күчә

Аннары мичтә пешә

Кызарып мичтән төшә.

Шуннан килә өстәлгә

Безгә куәт өстәргә.

Һәркемгә ипи кирәк!

Һәркөнне ипи кирәк!

Бәрәңгене икенче икмәк диләр. Чынлап та, балалар, бәрәңге быел бик уңган, хәтта чүпләп бетерә дә алмаганнар. Хәзер без шул бәрәңгене чүпләп ярышырбыз.

***“Кем тизрәк чүпләр?” уены***

***Җыр “Көз килә”***

**Сөмбелә:** Бигрәк матур җырладыгыз, биедегез,

Уйнадыгыз, шигырьләр сөйләдегез.

Барысы өчен рәхмәт сезгә.

Алдагы көннәрдә дә

Телим сезгә уңышлар.

Муллыкта, рәхәт тормышта

Яшәгез, нәни дуслар!

**Алып баручы:** Бүгенгә без хушлашабыз,

Бәйрәмне тәмамлыйбыз,

Күңелле дә соң бу көз!

**4.«Каурый, каз өмәсе»**

**Максат:** Балаларның татар халык йолалары, бәйрәмнәре турында белемнәрен баету, татар фольклоры белән таныштыру. Каз өмәсе йоласы турында әңгәмә. Элекке гореф-гадәтләрне искә төшерү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Җиһаз:** «Каз» йолкыр өчен тазлар, тастымаллар, бию өчен каурыйлар, утыргычлар, өстәл, самавыр, микрофон, компьютер.

**Бәйрәм барышы:**

Авыл өе күренеше. Көй яңгырый. Залга әбиләр  керә.:

“Каз канаты” җыры астында әбиләр җырлый-җырлый керәләр һәм урыннарга утыралар ( каз йолку башлана).

**Алып баручы:** среди обрядов осенне-зимнего сезона у татар особо выделяется праздник гуся "Каз өмэсе" Татарская молодежь с нетерпением ждала и тщательно готовилась к этому празднику.  Еще в начале лета молодая девушка приходила к хозяйке- владелице большого гусиного стада с просьбой взять ее осенью в помощь к себе. Хозяйка при этом выясняла не сирота ли девушка, трудолюбива и чистоплотна честна и скромна ли она. И не каждая девушка получала согласие хозяйки на свою просьбу. а та которая удостоилась этого сразу же начинала готовиться к осеннему празднику: вышивала фартук и полотенце, шила платье, вязала шаль. И все это отнюдь не случайно: ведь на этом празднике она могла встретить своего суженного и пообщаться с ним. Иных мест встречи в татарских деревнях попросту не было.

**Әби:** Әссәләмүгаләйкем, исән-сау килеп җиттегезме ахирәтләрем?  Менә мин сезгә эш әзерләп куйдым бит әле. Килгәнегез өчен биик зур рәхмәт! Өмәбезне башлап җибәрик, җайлап утырыгыз!

**Роза апа:** Кызым, кызым, кер әле.

**Рината:** Әйе, әбекәем. Ни булды?

**Роза апа:** Без кечкенә чагында каз өмәсе көнне балаларны каурый өмәсенә җыялар иде. И-и, кызык була иде безгә! Менә шул чакларны искә алып, мин сезне уенлы, җырлы, күңелле каурый өмәсенә чакырырга булдым. Әби – бабайларның гореф-гадәтләрен белү һәркайсыбызга фарыз эш ул!

Мин өмәгә оланнарны да чакырдым, алар хәзер килеп җитәрләр.

Күренмиләрме соң үзләре? (Тәрәзәдән карый.) Киләләр түгелме соң. Бәракалла,  киләләр!

**Рината:** Чыгып каршы алыйк үзләрен. Әйдәгез, әйдә, керегез! Исән–сау гына килдегезме?

**Ләйлә:**  Исән-сау җыелыштыгызмы, оланнар?

Сөбханалла – машалла, берегездән – берегез матур икән!

Менә сезгә әрҗә белән каурыйлар, сыдырылган йонны бу кәрзингә җыярсыз – мендәрне бик шәп кабарта ул каурый йоны. Соңыннан сыдырылган каурыйларны су буена чәчәрсез, бәбкәләрнең күп булуын теләп ятарлар алар.

**Балалар:** Ярар, әби, ярар.

**Тимур:**    Дусларым, канат сыдырасыбыз бар бит әле.

Әйдәгез әле, кем остарак, сыдырыр икән?

**Гөлнәфис:** Безнең халыкта «Эшләгәндә йөрәгең җилкенсен, ашагында колагың селкенсен» дигән мәкаль бар. Әйдәгез әле, җилкенеп эшләп алыйк. Кем сыдыра белми, миңа карагыз. Менә шулай эшлиләр.

**Әби (оныгына):** Кызым, син балаларны уйнат, җырлат, күңелле итеп эшләсеннәр. Мин сезгә коймак камырын яңартам, сезнең эшегез бетүгә әзер булсын. (Чыга)

***Бию:  “Каз канаты”***

**Роза апа:**  Ай-һай, сез биергә  бик оста икәнсез! Биеп, көлешеп эш беткәнен дә сизми калдык! Ә эш беткәч, уйнарга да ярый.

**Гөлнәфис**:Ай-һай, күп монда каурый, әбинең казлары бик күп булган, ахры.

**Ләйлә:** Әйе, безнең әбинең әфсене бар, диләр күршеләр, ел да егермешәр бәбкә үстерә ул.

**Доминик:**   Аларны үстерергә без дә булыштык шул:

Тилгән, тилгән,

Бәбкә алырга килгән,

Бер аягы тимердән,

Бер аягы камырдан, көш-көш!

дип тилгәннәрдән саклadык.

**Ләйлә:** Күз курка, кул эшли, дигән мәкаль дөрес икән. Каурыйлар бигрәк күп, ничекләр бетерербез дип курыккан идек, менә бит эшебез тәгәрәп бара.

Малайлар: әйдәгез,уйнап алыйк!

Балалар: әйдәгез,әйдәгез.

***УЕН: "Яшерәм яулык"***

Кулъяулыгым яшел, яшел,

Яшел чирәм астында.

Сиздермичә ташлап китәм

Бер иптәшем артына.

Роза апа: Күмәк эштә һәркем сынала аз сөйлә, күп эшлә. Шулай да гел сөйләшмичә дә күңелле түгел бит, балалар. Әйдәгез, оныкларга табышмакларга әйтик әле.

Әбиләр: әйдәгеез!

**Гөлнәфис:** Суда йөзә, бик күп илләрне гизә. Ул нәрсә?

**Балалар:** Каз, үрдәк.

**Ләйлә:** Соскы борын – бакылдык,

Күп сөйләшә - такылдык.

**Балалар**: Үрдәк.

**Роза апа:**Башы тарак, койрыгы урак,

Кычкыртып быргысын уята барысын.

**Балалар:** Әтәч.

**Әбиләр:** булдырдыгыз,балалар!

Әйдәгез бергәләп җыр  җырлар алабыз!

***Җыр “Алтын көз”***

**Роза апа:**Бии-уйный сылу кызлар,

Чыңлый чулпы төймәсе.

Борынгыдан килгән йола-

Татарның каз өмәсе.

**Гөлнәфис:**Каз канаты каурый – каурый

Коймак майларга ярый.

Уйнамагач та көлмәгәч,

Бу дөнья нигә ярый?

**Балалар:** кызлар, әйдәгез, уйнап алабыз.

***Уен “Чума үрдәк, чума каз” (т.х.у.)***

**Әби:** Коймагым да пеште. Әйдәгез, балалар, каз майларына манып коймак ашыйк, чәй эчик әле.

**Алып баручы:**Менә шулай каз өмәсен

Татарда үткәргәннәр.

Ә яшь кызлар күңел биреп

Бу эшкә өйрәнгәннәр.

**5.“Сабантуй” бәйрәме**

Татар көе уйный (диск №4 “Шома бас” 33 кисәк)

Бәйрәмчә бизәлгән зал, урамда шарлар эленгән. Гармун уйнап балаларны сабантуйга чакырабыз. Алар үзләренең бүләкләрен тапшыралар. Җырлар җырлап залга җыелалар. Бәйрәм башлана, татар күлмәкләре кигән кызлар сөлгеләр белән бииләр.

**А.б:** Исәнмесез, балалар, кадерле кунаклар, хәлләрегез ничек?

**Балалар:** Әйбәт.

**А.б:** Бүген без татар халкының олы бәйрәме – Сабантуйга җыелдык .

Сабантуй – ул хезмәт, дуслык бәйрәме.

Поздравляю вас с праздником Сабантуя и вместе споем песню “Сабантуй” (Диск “Уйный – уйный үсәбез”) 88 кисәк/

**А.б**: Как без танца, сабантуй

Не бывает.

Татарский танец

Всех вдохновляет.

Татарский танец ср.гр (Диск «Шома бас» 33 кисәк)

**А.б:** А сейчас дети расскажут стихи о Сабантуе.

**1 бала.** Күңелле сабан туйлары

Бүген бәйрәм, зур бәйрәм

Матур җырлар җырлый җырлый

Уйныйбыз әйлән-бәйлән.

**2 бала.** На веселый сабантуй

Мы позвали всех друзей.

Будем петь и танцевать

Дружно, весело играть.

**3 бала.** Сабан туе, Сабан туе

Хезмәт һәм бәхет туе.

Матур җырлар җырлап

Бәйрәм итик көн буе.

**А.б:** Сабантуй – самый веселый, любимый, народный праздник. Сабантуй проводят летом после окончания полевых работ. Когда летают бабочки, расцветают цветочки. И у нас расцвели разные, красивые цветочки.

Төрле төстәге чәчәкләргә күбәләкләр очып киләләр.

***Ср.гр №1 «Чәчәкләр һәм күбәләкләр" (Диск "Балалар бакчасында әдәп – әхлак тәрбиясе" 88 кисәк)***

Кечкенә күбәләкләр

Менә шулай очалар

Ак, яшел, сары, кызыл, зәңгәр

Бик матур чәчәкләр.

**А.б:** На цветочную поляну прибегают маленькие цыплята.

***Ср.гр №2 "Нәни чебиләр" – уен ("Балалар бакчасында әдәп әхлак тәрбиясе " 133 кисәк)***

Звучит татарская музыка и заходит Шурале.

**А.б:** Какой ужасный, злой и страшный

Наяву, а не во сне

Пришел лохматый, безобразный

К нам в детский сад Шурале.

**Шурале:** Я всем известный Шурале

Я не плохой, поверьте.

Любимое мое занятие –

Всех щекотать до смерти.

Я слышал что у вас праздник. Никакого праздника не будет, вы сегодня будете только смеяться и ничего не делать. Я буду вас щекотать, заставлять хохотать (играет с ними)

**А.б:** Шурале, наши дети с тобой хотят поиграть игру ст.гр «Шурале»
Шурале. Ой, меня похвалили. Мин әйбәт, матур, мин мактаганны яратам. Значит, я не буду вам мешать, я же люблю когда меня хвалят.

**А.б:** Нет, конечно, послушай как маленькие ребятки расскажут стихи.

**1 бала.** Зазвенел теплом июнь

Здравствуй, праздник Сабантуй.

После сева летним днем

Мы станцуем и споем.

**2 бала**. И нам пришли сегодня гости

Праздновать наш Сабантуй

Сабантуй, Сабантуй,

Пой, скачи, борись, танцуй.

**А. б:** Шурале, у нас дети и стихи читают, и поют, танцуют. А ты какой подарок приготовил нам?

Шурале: Ой, совсем забыл, я вам принес платок с татарскими орнаментами.

**А.б:** Какой ты добрый, Шурале, рәхмәт, а сейчас дети покажут игру с платочком. Игра называется «Кулъяулыгым".

**Шурале:** Мне очень понравилось у вас, но пора уходить домой, в лес (уходит)

**А.б:** У нас праздник продолжается, сейчас мы с вами посмотрим татарские костюмы.

Показ татарских костюмов. Презентация костюмов нашего региона.

Стук в дверь, заходит Батыр.

А.б.: Батыр, син кая югалдың?

Батыр: Мин сезгә бүләк алырга кибеткә бардым. (Түбәтәй күрсәтә)

**А.б:** Рәхмәт, әйдәгез әле, Батыр алып килгән түбәтәй белән уен уйныйбыз.

***Ст.гр. “Түбәтәй “ уены***

**А.б:** Батыр, безнең балалар Сабантуй турында шигырьләр дә беләләр.

1 бала. Снова песня зазвучала,

Подпевай ей и танцуй.

Мы сегодня отмечаем

Наш любимый Сабантуй.

**2 бала.** Сабантуй – веселый праздник

Праздник солнца и труда.

Пой, играй и смейся громко

Веселись, как никогда.

**А.б:** Батыр, у нас дети из подготовительной группы скоро идут в школу и обещают хорошо учиться. Вот сейчас они тебе покажут какие они будущие примерные ученики.

***Игра “Кәрия-зәкәрия” (подготовительная группа)***

**А.б:** Батыр, әйдә, биеп тә күрсәт инде.

Татарча ирекле бию

После пляски всех зовем на соревнования.

Игры на улице.

Музыка

1) Татарская плясовая (диск «Шома бас» ) №33 УМК

2) Песня Сабантуй №88 (диск «Уйный-уйный үсәбез») УМК

3) Средняя (2) – тат танец №33 (диск «Шома бас») УМК

4) «Кубәләкләр, чәчәкләр” –игра (ср 1) диск УМК

“Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” №88УМК

5) “Нәни чебиләр” – игра (ср 2) (диск “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе”) №133 УМК

6) Шурале заходит

7) Игра “ Шурале” – ст.гр

8) Татарская плясовая (диск «Шома бас») №33 УМК

9) “Кулъяулыгым” (пианинода)

10) Выход в татарских костюмах (диск “Туган телдә сөйләшәбез”) №48 УМК

11) Батыр заходит (Игра на гармоне)

12) “Түбәтәй” – игра ст.гр (пианинода¬)

13) “Кәрия –Зәкәрия” – игра подг.гр (“Җырлап-биеп уйныйбыз”) №22

14) Танец тат – подг.гр (диск “Туган телдә сөйләшәбез”) №11 (2-3 яшь)УМК

15) Плясовая тат-я –батыр танцует со всеми (диск «Шома бас» -№33) УМК

**6.“Нәүрүз – язгы бәйрәм”**

**Максат: 1**. «Нәүрүз» бәйрәме тарихы белән таныштыру.

2.Яз турында сәнгатьле итеп шигырьләр сөйләү,җырлау

күнекмәләрен үстерү.

3. Халкыбызның гореф-гадәтләренә,милли йолаларына

мәхәббәт тәрбияләү.

**Алып баручы:** Исәнмесез балалар! Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар! Менә салкын кыш үтеп китте, ямьле җылы яз җитте. Яз белән бергә Нәүрүз бәйрәме килеп җитте!

Нәүрүз – язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул. Нәүрүз сүзе яңа көн дигәнне аңлата. Нәүрүз бәйрәме – ул игелек, дуслык бәйрәме. Бу гүзәл, язгы бәйрәм көнендә кешеләр бер-берсенә кунакка йөриләр, бер-берсенә булган үпкәләрен оныталар, җырлыйлар, бииләр, рәхәтләнеп күңел ачалар. Бу бәйрәмнең хуҗасы — Нәүрүзбикә.

Нәүрүз котлы булсын! Без сезне күңел ачарга чакырабыз!

*( Балалар “Яз җыры”н башкаралар. Утыралар урындыкларга).*

**АБ:** Нәүрүз бәйрәме  башланды, ә Нәүрүзбикә юк! Әйдәгез әле балалар, без аның турында шигырь сөйлик, бәлки ул килеп тә җитәр.

**Бала 1:** Елгада бозлар кузгалды.

Елмая, кол кояш.

Урамнар буйлап атлый,

Ямьле һәм күнелле яз.

**Бала 2:** Әй яз-матур, яз-матур,

Хуш килсең, үз бире.

Кунак булып килер дип,

Куптән көттек без сине.



**Бала 3:** Кояшлы көннәре белән

Ямьле яз килеп житте.

Бу жырны безгә бәйрәмгә

Ямьле яз бүләк итте.

**Бала 4:** Әй дускайлар, дускайлар,

Житте ич Нәурүз айлар.

Эшегезне ташлагыз,

Бәйрәмгә ашыгыгыз!

**Нәүрүзбикә:** Исәнмесез балалар! Мин ерактан килдем сезгә язлар иленнән,

Урман аланынын ал чәчәкләр үскән жиреннэн.

Зәнгэр болытлы, Лэйсән янгырлары белән

Килдем язгы сулар кебек ашкынып.

**Балалар:** Исәнмесез, Яз кызы – Нәурүзбикә!. Без сине бик көттек!

**Алып баручы:** Хуш киләсен, Нәурүз, түрдән уз! Жылы Ләйсэн янгырлардан соң жир йөзе яшәреп, шау чәчәккә төренер. Нәүрүзбикә, без бик шат сине кабат күрүебезгә. Син безгә беренче чәчәкләр алып килдең**.**

**Нәурүзбикә:** Әйдәгез, кызлар, чәчәклэр белән биеп алыйк әле.

***Бию"Умырзая" (чәчәклэр белэн)***

**Алып баручы:** Әйдәгез әле, балалар, без яз турында жыр беләбез. Шул жырны жырлап утик әле.

***( "Яз житә" жыры)***

**Нәурузбикә:** Балалар, ә хәзер, әйдәгез, бергәләп уйнап алыйк.

***"Там, там, тамчы там" уены (татар халык көе һәм сузләре)***



Уенчылар, пар-пар булып, кулга-кул тотынышып бер-бер артлы басалар. Алар бергэлэп тубэндэге жырларны жырлыйлар һәм бию хәрәкәтләре ясыйлар:

Там, там, тамчы там, *алга баралар*

Тамганынны яратам *артка таба чигәләр*

Тамган тамчыларга карап, *кара-каршы басып кул чабалар*

Мин жырларга яратам

Без уйныйбыз, уйныйбыз, *тугәрәк ясап әйләнәләр*

Якты көннән туймыйбыз.

Кулны –кулга чаба-чаба, *кул чабалар*

Көләбез дә жырлыйбыз

***(Уеннан сон балалар урындыкларга утыралар)***

**Алып баручы :** Яз нурлары- көмеш нурлар

Сибелсен жиргә.

Яз шатлыгы, яз бәхете,

Телибез сезгә

Язлар, җәйлэр имин килсен,

Кук йөзе аяз булсын.

Барчабызга сәламәтлек,

Бәхетләр алып килсен!

*(Балалар музыка астында чыгып китэлэр)*

## 7. “Карга боткасы” бәйрәме .

**Максат:** Балаларда туган илгә, туган шәһәребезгә, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләү. Төрле милләт халкының иҗатын, тарихын, гореф-гадәтләрен өйрәнүне дәвам итү һәм аңа кызыксынучанлык хисе тәрбияләү.

**Бурычлар:**

1. Балаларның төрле жанрдагы музыкаль әсәрләрнең эчтәлеген аңлау сәләтен үстерүне дәвам итү, әсәрләрдә чагылган хисләргә карата эмоциональ мөнәсәбәт булдыру.

2. Бәйрәмне әзерләүдә һәм үткәрүдә балаларның үзләренең, әти-әниләрнең катнашу активлыгын үстерү.

3. Шигырьләрне, әкиятне сәнгатьле итеп сөйли белү күнекмәләрен камилләштерү, әкият буенча тамаша уйнау һәм рольләрне башкару осталыкларын үстерүне дәвам итү, геройларның кылган эшләренә дөрес бәя бирергә өйрәтү.

**Җиһазлар:**

агачлар, магнитофон,шарлар,дуслык турында рәсем, сый җыю күренеше өчен декорацияләр.

**Методик алымнар:** әңгәмә, уеннар, күрсәтү, сәхнәләштерү.

**Күңел ачу иртәсенең барышы:**

Зал матур итеп бизәлгән: бер якта 2өй тора, залның түрендә аланлык, бүрәнәләр кырыйда. Залга кара-каргалар очып керә.

**1 нче карга:**
Кар-кар-кар,
Без кара каргалар ,
Без иртә яз киләбез,
Илгә яз китерәбез.
**2 нче карга:**
Карр, карр, карр,
Туем җитте, барр, барр.
Ярма, күкәй алып бар,
Карр, карр, карр!

Каргалар очып чыгып китәләр. Балалар залга керәләр, ярым түгәрәккә басалар.

**Кыз:** Ачылды ак калын юрган,
Исте апрель җилләре.
Кошлар кайта, сагындырып
Туган үскән җирләрен.
Көннәрен юлда үткәреп,
Куанышып очалар.
Канатларын да күтәреп,
Яз китерә ич алар.

**Алып баручы:** Әйе, балалар, безнең илебезгә яз килеп җитте. Яз көне карлар тиз эреп бетә, агачлар яфрак яра башлый, үләннәр яшелләнә, игеннәр дымга туена, кошлар кайта туган якларына.

***ҖЫР "Яз килә". Җырдан соң балалар бүрәнәләргә утыралар.***

**Алып баручы.** Борын-борын заманда кешеләр ни өчен яз булганын белмәгәннәр, ди. Алар язны җылы яклардан кара каргалар алып килә икән, дип уйлаганнар. Шуның өчен карлар эреп, сулар ага башлагач каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясый торган булганнар. Аны "Карга боткасы" дип атаганнар. Менә шушындый яшел аланда уйнаганнар, җырлаганнар, күңел ачканнар. Ахырдан ботка пешереп, ашый торган булганнар.Без дә бүген карга боткасы бәйрәменә җыелдык, ә безнең әле бернәрсәбез дә әзер түгел. Әйдәгез, бәйрәм өчен нәрсәләр кирәклеген искә төшерик .

**Җаваплар:** Ярма, сөт, йомырка, май.

**Алып баручы.** Элек бәйрәм өчен сыйны балалар өй буенча җыеп йөргәннәр. Без дә шулай итик

**Балалар сый җыярга китәләр.**

**Малай:**
Өйдәме, түтәй,
Бир зинһар күкәй.
Бирсән безгә өч күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй.
Әби өйдән чыгып йомырка бирә. Балалар рәхмәт әйтәләр.

**Малай:**
Кызганма, түтәй,
Май кирәк безгә.
Ярма да кирәк
Карга туена бар да кирәк.
**Кыз:**
Шикәр кирәк, тоз кирәк, чыгар түтәй тизрәк.
**Алып баручы:**
Ярма, сөт, йомырка, май!
Казылык та бир түтәй.
Өй эченнән әти белән әни чыга.
**Әни:** Менә, балалар, бар да бар, май да сөт тә.

**Әти:** Күкәй дә, ит тә. Ботка бик тәмле булыр.

Балалар әби белән бабайга, әти-белән әнигә рәхмәт әйтәләр,аланга китәләр

**Малай :** Безне сөендергән өчен сезне Ходай сөендерсен. Әйдәгез сез дә безнең белән карга боткасы ашарга.

Әби белән бабай, әти- белән әни рәхмәт әйтә-әйтә, балаларга иярәләр.

**Алып баручы:** Менә, балалар, сыйлар да булды. Хәзер инде безгә учак ягырга кирәк.

**Бабай:** Була ул! Хәзер мин аны ягам.

**Әти:** Бабай – әби сез балалар белән ял итегез, без учакны хәзер үзебез үрләтеп җибәрербез.

**Әни :** Ботканы да пешерә торырбыз..

**Бабай:** И-и- и әбисе, кара әле монда, нинди күп милләт балалары җыелган бит безнең карга боткасы бәйрәменә.

**Әби:** Чынлап та бабасы, күрми дә торам, нинди матурлар.

**Алып баручы:** Әйе бабакай, әбекәй без үзебезнең бәйрәмебезгә башка милләт балаларын да чакырдык күңел ачарга. Алар безнең бәйрәмебезгә буш кул белән килмәгәннәр, күчтәнәчләр белән килгәннәр.

**Әби:** Шулаймыни балакайларым. Ниндиерәк күчтәнәчләр икән?

**Бала:**
Карап тормый ара еракка
Дуслар килә безгә кунакка.
Дуслык безнең тормыш үзәге
Дуслык безнең бәйрәм бизәге.
Төрле костюмнар киеп,
Йөрибез җырлап-биеп
Атадык без бу бәйрәмне
**“Карга боткасы ”,диеп.**

***Башкорт биюе.***

**Әби:** Бик рәхмәт, күңел күчтәнәчләрегезгә. Балалар, сез бәйрәм итә торыгыз, без бабакаегыз белән ботка ни хәлдә икән шуны белешеп килик.

**Алып баручы:** Хөрмәтле, балалар, кунаклар, ботка пешә торсын, ә без шул чакта бераз җырлап, уйнап алыйк..

***“Бәйрәм җыры”.***

**Әни:** Мондый тәртипле, мәрхәмәтле балаларны күргәч, биисе килә башлады. Хәтерлисеңме, әтисе, яшь чакларда бик матур итеп бии идек бит. Сезнең дә, балалар, күрәсе киләдер.

**БИЮ “Татар халык биюе” .**

**Әби:** Эх, бар иде яшь чаклар. Әйдәгез әле, бергәләшеп шул чакларда уйный торган уенны уйнап алыйк.

***Татар халык уены. “Йөзек салыш”***

**Әби:** Балакайларым безнең карга боткабыз пешеп җитте. Без сезгә кайтуыгызга табын әзерли торабыз, сездә озак тоткарланмагыз табыннарда боткагыз сунмасын.

**Әти-әни:** Балалар сезне төркемдә карга боткасы көтә . Хөрмәтле кунаклар, безнең сезне дә Карга боткасы белән сыйлыйсыбыз килә.Зал түренә рәхим итегез.

## 8. “Әбиемнең –серле сандыгы”

**Максат:**

1.Балаларның милли киемнәр турында алган белемнәрен гомумиләштерү.
2. Әдәплелек турында белемнәрен тирәнәйтү.
3. Татар халкына хас булган кунакчыллык тәрбияләү.

*Зал өй кебек бизәлгән. Өй күренеше. Түрдә сандык, алдарак борынгы ашъяулык япкан өстәл. Өстәл өстендә самовар, чәйнек, чынаяклар һәм татар халык ашлары (өчпочмак, чәк-чәк, бәлеш, түгәрәк ипи) куелган.*

**Кыз:**

Әбиемнең күңел сандыгы!
Нинди серләр саклый икән ул?
Гомер буе җыйган хәзинәме,
Әллә инде күңел бизәгеме,
Нинди серләр саклый икән ул?
Әбиемнең күңел сандыгын
Бер ачасы иде, ачасы…
Әби-бабам белгән йолаларны,
Халкыбызның күңел җәүһәрләрен
Бер ачасы иде, ачасы.
Әбиемнең күңел сандыгы
Кызыктыра инде күптәннән.
Ач, әбием, безгә күңелеңне,
Яшь буынга мирас булып калсын,
Бер хәзинә калсын үткәннән.

***(Шигырьне укыганнан соң кыз балаларны һәм тәрбиячене чакыра)***

**Кыз:** Дусларым,апалар керегез әле. Керегез әле.

**Тәрбияче:** Миләүшә,нәрсә булды?

**Миләүшә:** Нинди сандык бу?

*Шулвакытта әби килеп керә*

**Әби:** И-и-и,балакайлар,нинди тәүфыйклылар,кунаклар бар икән.

**Миләүшә:** Әбекәй,бу нинди сандык?

**Әби:** И,балалар,минем яшь чактагы сандык ул.

**Миләүшә:** Әбекәй, әбием дим, әйдә ачыйк инде шул сандыгыңны, карыйк әле.

**Әби:** Шулай дисезме, ягез, ачыйк алай булгач. Тезелешеп утырыгыз яныма.(салмак кына көй яңгырый, әби сандыкны ача-ача сөйли, әйберләрен күрсәтә)

**Әби:** Менә монысы алъяпкыч. Татар кызларының алъяпкычлары канатлы булырга тиеш. Чиккән алъяпкычлар зифа буйлы кызларга бигрәк тә килешеп торган. Киләчәктә сез дә шулай милли алъяпкычлар ябып йөрерсез әле.

***(Бер бала алъяпкычны бәйләп ала да шигырьне сөли башлый)***

Алъяпкычымның бизәге
Әллә кайдан күренә.
Аллы-гөлле чәчәк төшкән
Килешәдер үземә.

**Әби:** Бала итәкле күлмәк тә татар кызларының милли киеме. Итәкләре никадәр күп булса, шулкадәр матуррак санала, кызларның балтырларын чит-ят күзләрдән каплый.

Ә менә монысы түбәтәй була.Түбәтәй чигә һәм тегә белгән кеше алтын куллы оста санала иде. Кара бәрхеткә ука яисә сәйлән чигелгән түбәтәйләрне бәйрәмнәрдә кешелеккә генә кияләр. Ә көн дә кияр өчен сырып тегелгән, менә шундый кара бәрхет түбәтәйләр була. (Бер малайның башына кидерә). Карагыз әле, ничек килешә.

**Тәрбияче:** Ә кызлар нәрсә кия башларына?

**Әби:** Ә кызларга - калфак. Калфак чигү һәм тегү бигрәк тә зур осталык таләп итә. Менә бу чуклы калфакны үзем чигеп кидем. Ак сәйлән белән күпертеп эшләнә ул. Элегрәк мондый калфакларны бай хатыннары гына кия иде, ә кыз балалар түбәтәй рәвешендә эшләнгән, чигүле кәттәҗине киеп йөрделәр. Яле, кызым, шушы кәттәҗине киеп җибәр әле. Күрегез әле, ничек чибәрләнеп китте. Теләсәгез, сезне дә кәттәҗи чигәргә, калфак тегәргә өйрәтермен. Минем кызларым үзләре чиккән кәттәҗиләрне киеп йөриләр.

Менә бу читекләрне киеп,бик матур итеп бии идек.

***(Икенче бала кулына ала һәм шигырьне сөйли)***

Бизәк төшкән итекләрне
Читекләр дип йөргәннәр.
Аларны татар кызлары
Бәйрәмнәрдә кигәннәр.

**Миләүшә:** Әбием, әбием дим, әнә шул төенчегеңдә нәрсә бар соң (сандык эченә үрелеп караган кыяфәттә сорый)

**Әби:** Әлеге янчыкны әйтәсезме? Ягез карыйк әле (ачып карыйлар). Анда минем чулпыларым сакланган.

**Тәрбияче:** Әбекәй, чулпыларың турында да сөйлә әле балаларга.

**Балалар:** Сөйлә әбекәй, сөйлә ( хор белән әйтәләр).

**Әби:** Чулпылар кызларның чәчләренә тагылып, аларны матурлый торганнар иде. (куеп күрсәтә – бер кызның чәченә, тәрбияче булыша, әби сөйли тора). Аларны без бәйрәмнәрдә, аулак өйләрдә генә тага торган идек.

**Миләүшә:** Ә аулак өй дигәннәрегез ничегрәк була иде соң ул, әбием?

**Әби:** И, ул аулак өйләр.(әкрен генә көлә. Музыка үзгәртелә). Егетләре дә шунда булыр иде., Егетләр гармун уйнап, җырлап урам әйләнерләр иде, кызлар өйләрдә кешегә сиздермичә генә егетләрне көтеп утыралар иде**.**

**(Әби уйланып басып тора. Шулвакыт гармун тавышы ишетелә.)**

**Бер кыз:** Кызлар! Кызлар! Егетләр килә түгелме? Кертәбезме?

**Икенче кыз:** Кертик, кызлар! Әзрәк утырырлар да кайтып китәрләр**.**

**Егетләр:** Исәнмесез, кызлар-йолдызлар!

**Кызлар:** Исәнмесез! Егет сезгә кем кирәк?

**Егетләр:** Кара кашлы кыз кирәк! Кызлар ачыгыз инде ишегегезне!

**Кызлар:** Ишек бавы бер алтын

Безнең кызлар мең алтын!

**Егетләр:** Кызлар кертегез инде.

**Кызлар:** Ярый инде керсеннәр! (егетләр керәләр) Егетләргә бер җырлап күрсәтик әле. (”Ал чия төпләрендә” көенә җырлыйлар).

Егетләр килгән, егетләр.
Нигә килгәннәр икән?
Тыңлап карыйк, җырласыннар,
Нәрсә диярләр икән.
**Егетләр:**

Ал чия төпләрендә,
Гөл чия төпләрендә.
Сулар сибеп үстерәләр
Тәрәзә төпләрендә.

Сандугачның балалары
Талга кунганнар икән.
Кызларыгыз бигрәк чибәр,
Бигрәк уңганнар икән.

**Бер кыз:** Бигрәк матур җырлыйсыз икән.

**Миләүшә:** Әбекәй, үзегез уйнаган уеннарны безгә дә өйрәт әле.

**Нурия әби:** И, балалар, үзем генә өйрәтә алмам шул. Кая, күршекәемне чакырып керим әле булмаса. (“Бибинур, ахирәт! Күршеңдә – аулак өй. Кер әле, кер, тизрәк! дигән тавышы ишетелә.)

**Бибинур әби:** (үзе күренми) Кунагым бар иде шул.

**Нурия әби:** Ә-ә, ярар, ярар, кунагың белән кер. Кул эшләреңне дә алып кер.

**Бибинур әби:** (кунагы белән керә) И-и, шушы Нурияне! Яшь чагында да шулай җор иде, хәзер дә шул. Картаеп беткәч, нинди аулак өй икән инде ул?

**Нурия әби:** И ахирәт, кызлар аулак өйгә җыелганнар. Берәр уен өйрәтүне сорыйлар. (Исәнләшәләр, утырып дога кылалар).

**Миләүшә:** Безгә бәет яки мөнәҗәт өйрәтсәгез дә ярый.

**Бибинур әби:** Зәмзәмия, мөнәҗәтне син оста әйтәсең бит, әйдә әле.

**Зәмзәмия әби: (**мөнәҗәт әйтә) БисмиЛләһир-Рахмәнир-Рахим.

Килеп кердем өегезгә,
Дога кылдым түрегездә.
И Аллаһым, иман нуры
Балкып торсын йөзегездә.

Мәҗлесегез күркәм булсын,
Өегезгә фәрештә тулсын,
Догаларым кабул булсын,
Әрвахларыгыз шат булсын.

**Нурия әби:** Ахирәтләр, әйдәгез, боларга югары очта кичке уен вакытында егетләр белән уйный торган уеныбызны өйрәтик.

**Бибинур әби:** Теге “Чума үрдәк, чума каз”нымы?

***(“Чума үрдәк, чума каз” уены уйнала)***

Чума үрдәк, чума каз,
Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата шул, ярата
Тирән күлне ярата шул, ярата,

Айдар үзенә иптәш эзли,
Белмим кемне ошата?
Алияне ошата шул, ошата,
Алияне ошата шул, шул.

***(Җыр кабатлана, исемнәре үзгәртелә)***

**Бибинур әби:** Кара әле, Нурия, без бит җырлап-уйнап кына утырмый идек, табышмаклар да әйтешә идек.

**Нурия әби: Әйе шул. Әйдә әле, Бибинур, башла.**

**Бибинур әби:** Башы – мунчала, койрыгы – сүс. (Җавабын таба алмыйлар). И, балалар, сез таба алмассыз шул аның җавабын. (Мич башыннан чабата алып күрсәтә). Чабата ул. Элек әтиләр чабата үреп бирәләр иде. Төшеп калмасын өчен, артына киндерә, сүс бау да тагалар. Ә яз, көз көннәрендә, пычрак кермәсен өчен табанына шакмак кагып, күтәртмә ясый торганнар иде.

**Нурия әби:** Безнең заманда аулак өйләр күңел ачу кичәләре генә түгел иде. Кышкы озын кичләрдә кызларның уңганлыгы өлгерлеге тикшерелә иде. Анда без бирнәләр әзерли идек. (Сандыктан алып күрсәтә). Ә болары – Казан сөлгеләре. Әбиләребез үзләре тукып эшләгән. Кайсы гына егетнең иңенә ятмаган да, нинди генә батырларга бүләк булмаган бу сөлгеләр.

**Зәмзәмия әби:** Монысы “күкрәкче” дип атала. Беренчедән, ул бизәнү әйбере, икенчедән, хатын-кызның күкрәген ят күзләрдән каплаган. Бала имезгән вакытта да бик уңайлы булган. Бирнәгә дип бик күп күкрәкче әзерли торган идек тә кияүнең туганнарына бүләк итә идек.

**Нурия әби:** Мендәр тышларын да бик тырышып чигә идек. Карагыз әле, никадәр хезмәт, күңел җылысы салынган бу бизәкләргә. (Сандыктан алып күрсәтә бара). Менә монысы – түрләмә, өй түренә, тәрәзә өсләренә эләр өчен. Караватка куяр өчен кашагасы чигелеп, читенә кулдан бәйләнгән челтәр ялгана.

Ашъяулыкны чигеп, кырыен бала итәкле итеп әзерлиләр. Аякчу, тастымал, намазлык, суккан паласлар – барысы да бирнәгә дип әзерләнгән**.**

**Миләүшә:** Рәхмәт сезгә, әбекәйләр! Күңел сандыгыгыз бигрәк бай икән, безне дә күп нәрсәләргә өйрәттегез. Безнең бу җырыбыз сезгә рәхмәт сүзе булып яңгырасын.

***Җыр "Әбием, әбекәем" Р. Бакиров сүз, Р. Сәрвәров көе***

**Тәрбияче:** Хәзер бергәләп күмәк биеп тә алыйк.

***Кунакларны балалар биергә чакыра.***

**Нурия әби:** Минем дары тәбикмәгемнән дә авыз итегез. Сезгә атап пешергән идем лә, онытып китә язганмын. Рәхим итегез. Балалар сез дә сыйланыгыз.

**Тәрбияче:** Әбиләребез сезне - нәни оныкларын, тәрбияләүгә күпме көч куялар. Аларны яратырга һәм хөрмәтләргә кирәк.

**9. “День родного языка, «Туган тел»!бәйрәме.**

**Звучит музыка на песню «Туган тел»(сл.Г.Тукая)**

**Ведущий1 .**

И туган тел, и матур тел
Әткәм-әнкәмнең теле.
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

**Ведущий 2.**

О, язык родной, певучий,
О родительская речь!
Что ещё на свете знал я,
Что сумел я уберечь?

**Ведущий 1.**

Исәнмесез, балалар, тәрбиячеләр! Хәерле көн! Бүген без туган телебезгә багышланган кичәгә җыелдык. Барлык илләрдә дә 21 февраль туган тел көнебуларак билгеләп үтелә.

Һәр кешенең иле бер генә булган кебек, туган теле дә бер генә. Телгә баланы аның иң газиз, иң якын кешесе – әнисе өйрәтә, шул телдә аңа бишек җырлары җырлый, иркәли. Шуңа күрә аны халык ана теле дип атый.

**Ведущий 2.**

Здравствуйте, ребята! Для чего же мы собрались сегодня? 21 февраля каждый год весь мир отмечает «Международный день родного языка». В мире существует очень много языков. Ещё когда вы только родились и были совсем крохами, ваши мамочки напевали вам колыбельные песни на вашем родном языке. А как вы понимаете, что такое родной язык? (тот, на котором мы разговариваем). На каком языке вы разговариваете? Какие бывают языки? Почему люди учат языки других народов?

**А теперь дети прочитают стихотворение о родном языке.**

**Ребенок1.**

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.

**Ребенок 2.**

На «Пять» татарский надо знать
И русский надо знать на «пять».
Вокруг два языка слышны.
Они нам дороги, нужны.

Какие пословицы о языке вы знаете?
Язык до Киева доведет.
Слово не воробей, вылетит – не поймаешь.
Держи язык за зубами.
Видна птица по перьям, а человек — по речам.
Язык острее бритвы.
Теле барның иле бар.
Әдәп башы – тел.
Дөньяда иң татлы нәрсә дә тел, иң ачы нәрсә дә тел.

**Ведущий 2.** Отгадайте загадку:

Эти яркие сестрички,
Дружно спрятали косички
И живут семьей одной.
Только старшую открой,
В ней сидит сестра другая,
В той еще сестра меньшая.
Доберешься ты до крошки,
Эти девицы -…(Матрешки)
***Танец матрёшек.***

**Ребенок3.**

Без – татарлар! Шушы исем белән
Җирдә яшәү үзе зур бәхет.
Яшибез без бу җирдә

Бар халыклар белән берләшеп.

**Ребенок 4**

Наш Татарстан
Дружбой славится
Нам жить в Татарстане
Очень нравится.

**Ребёнок 5**

Йөри безнең бакчага
Бик күп төрле балалар.
Төрле-төрле телләрдә
Сөйләшә белә алар.
Төрле костюмнар киеп
Йөрибез җырлап-биеп.
Атадык без бу бәйрәмне
Дуслык бәйрәме диеп.

**Ведущий 2**

Наш детский сад посещают дети разных националностей. Каждый народ говорит на своем родном языке: татары – на татарском, русские – на русском, чуваши – на чувашском, башкиры – на башкирском. У каждого народа свои обычаи, традиции, свои наряды. Поскольку мы живем в Татарстане начнем ознакомление с татарами, их одеждой, традициями и их бытом. Татары основное население Татарстана. Как называется столица нашей Республики? Татарский народ очень самобытный, богатый традициями и своей культурой.

***Слайд 2,3.***

*Мы с вами познакомились многими татарскими народными сказками и играми на занятиях, сейчас давайте вместе сыграем в народную игру*

***Татарский танец***

***“Кәрия-Зәкәрия”***

*Балалар түгәрәк ясап басалар һәм иптәшләреннән берсен уртага чыгаралар да аның турында җырлыйлар. Кушымтаны җырлаганда уртада торучы бала бии, башкалар кул чабалар.*

**Ведущий1:**

Прав был великий татарский поэт Г. Тукай.
С народом России мы песни певали,
Есть общее в нашем быту и морали
Один за другим проходили года,
Шутили, трудились мы вместе всегда
Вовеки нельзя нашу дружбу разбить
Нанизаны мы на единую нить.
**(Слайд 6,7).**

Русские костюмы тоже очень красивые, в зависимости от возраста, статуса и по какому поводу одевается костюмы немного отличаются**.**

***(Башкорт көе яңгырый)***

**Ведущий 2:** На территории Поволжья живет башкирский народ. Они разговаривают на своем башкирском языке. Издревле они славились тем, что были искусными охотниками. Они разводили лошадей и из лошадиного молока делали очень полезный для здоровья напиток-кумыз. Башкирские женщины ткали ковры, вышивали на полотенцах**.**

**(Слайд 8)**

**1 ребёнок:** Башкирский костюм очень богат декоративной отделкой. Основу башкирского костюма составляет нательное платье (кулдэк) с оборками и жилеткой.

**2 ребёнок:** Самым богатым элементом костюма были нагрудники (сэлтэр). Они оберегали девушку от злых духов.

**3 ребёнок:** Украшения у женщин: серьги,браслеты, перстни – изготовлялись из серебра,кораллов, бисера и монет. Чем больше украшений, тем богаче девушка!

**4 ребёнок:** Праздничный женский головной убор назывался калябаш. Высокая шапочка с широкой лентой. Расшивалась бисером и серебром**.**

**5 ребёнок:** У древних башкир существовало поверье, как спастись от нечистой силы. Если за девушкой гналась нечистая сила, то она должна была бросить какую-либо дорогую часть из своей одежды и помолиться.

Тогда погоня прекращалась.

Ребята, давайте попробуем с вами поздороваться и сосчитать до 10 на разных языках (на русском, татарском, английском, немецком, марийском, турецком и др.)

***Татарская народная игра “Чума үрдәк, чума каз”.***

Балалар бер-берсенә карап (ике саф булып) тезелешеп басалар. Бер бала так кала, ул балаларга карап баса. Балалар бала исемен әйтеп җырлыйлар. Җыр бетүгә, так калган бала саф арасыннан үтә, үзенә пар таба, артка барып басалар. Ялгыз калган бала алга чыгып баса, уен дәвам итә.

***Җыр “Кояшлы ил”***

**Ведущий 1.**

Телебезне күңел гөле итеп
Саф көенчә саклыйк гомергә.
Рухи дөньяң булсын халкың моңы
Туган телең йөрсен синең белән бергә.

**Ведущий 2.**

Родной язык – цветок души.
Ты сохрани его на веки.
Чтоб дети, внуки вспоминали
Родной язык уберегли.

**Ведущий 1.**

Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар, менә сезнең белән саубуллашыр чак та җитте. Сау булыгыз! Бүгенге бәйрәм кичәсе сезнең күңелләргә дәрт өстәсен.

**Ведущий 2.**

Дорогие друзья! Вот и подошел к концу наш праздник. Пусть наша встреча останется добрым воспоминанием в ваших сердцах. Успехов вам и доброго здоровья.

**10. Абдулла Алиш иҗатына багышланган бәйрәм кичәсе .**

**Максат:**

Язучы иҗаты белән танышуны дәвам итү.
Балаларның Алиш әкиятләре турындагы белемнәрен ныгыту.
Киләчәк буын кешеләрндә әниләргә карата ихтирамлылык, дуслыкның кадерен белү, сер саклый белә кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү.

**Алып баручы:** -Исәнмесез,балалар!
Кәефләрегез ничек?
-Туган телне,Тукай телен
Өйрәнергә дип килдек!
Балалар, бүген без татар язучы Абдулла Алиш турында сөйәшербез.(Слайд)
**Алып баручы:** 15 сентябрьдә Абдулла Алиш туганына 110 ел тулды. Ул Татарстан республиканың Спас районының Куюки авылында туган. Аның әтисе белән әнисе крестьяннар булган. (Слайд).

**Алып баручы:** Абдулланың әнисе шигырьләр һәм кыска хикәяләр язган. Язучы сәләте Алишка димәк әнисеннән күчкән. Аның әтисе бик укырга яраткан, өйләрендә күп китаплар булган. Үскәч Абдулла Алиш шигырьләр, хикәяләр һәм әкиятләр язган. Алиш биктә балаларны яраткан, алар да аны ятатканнар. Аның әкиятләрен йотлыгып-йотлыгып тыңлаганнар.Балалар Алишны “Әкияттәге абый” дип атаганнар.

Кемгә генә якын түгел
Әкиятләр дөньясы?!
Әкиятне яраталар
Кечесе һәм олысы.

***Җыр “Где живёт сказка”***

Урман күренеше.

Сихри моңлы көй яңгырый. Татарча киенгән малай килеп чыга.

**Малай:** Нинди җиргә килеп чыктым мин? Әллә кая адаштым. Малайлар белән ук ясарга усак агачы ботагы кисергә килгән идек бит.

Нинди матур урыннар!

Куян булып киенгән бала чыга.

**Малай:** Син кем?

**Куян:** Мин,куян кызы.

**Малай:** Аягыңда нәрсә ул синең?

**Куян:** Бу киез итекләр, аларны миңа әнием бүләк итте.  Мин хәзер аларны бер дә салмыйм,сүзне тыңлыйм. Ә син нишләп берүзең урманда йөрисең.

**Малай:** Мин әнием сүзен тыңламадым, дусларым белән урманга киттем, менә хәзер адаштым, ничек өйгә кайтасы юлны табарга, белмим (елый).

***"Әнкәй" шигырен балалар сөйлиләр.***

**№1 бала**

Кая барма-шунда, әнкәй йөзе
Кая барсам-әнкәй күңелдә.
Әни генә шулай синең өчен
Җанын биреп яши гөмергә.

**№2 бала**

Авырсаң янда тора ул.
Төн буе керфек какмый
Ул саулыгында кызганмый
Ул безне саклый-саклый.
***Кызлар башкаруында "Бишек җыры" яңгырый.***

**№3 бала**

Рәхмәт яусын безнең әнкәйләргә
Аларгадыр бөтен авырлык.
Әнкәйләргә якты йолдызлардан
Я кояштан һәйкәл салырлык.

**Куян кызы:** Елама, мин сиңа булышырмын. Әнә тегендә ике чыршы утыра, шуннан уңга таба китерсең, анда алан булыр, аланны кояш чыккан якка таба кисеп чык, шуннан юл күрерсең. Юлдан чыкмый 4-5 сәгать барсаң, авылыңа килеп чыгарсың. Онытма беркайчан: Әниләр сүзен тыңларга кирәк!

**№4 бала**

Җан җылысын тоя күңелебез
Әнкәй көчен тоя кулыбыз
Үпкәләмәсеннәр!
Әнкәйләргә гел изгелек кенә кылыгыз!
Куян кызы саубуллашып китеп бара.

**Малай:** Рәхмәт куян кызы. (Малай китеп бара.Әзрәк баргач,аңа ике әтәч очрый)(Әтәч костюмнарында ике бала чыга)

**Әтәчләр:** Мин сине хәзер тукмыйм, ә мин сине чукыйм!(кычкырышалар)

**Малай:** Ә сез нишләп йөрисез монда, әтәчләр?

**Әтәчләр:** Менә, әбине тыңламадык: и сугыштың и талаштык, беребез гел тукмарга тотынды, беребез-чукырга. Әби түзәлмәде куды да чыгарды безне. Чыгып очтык хурлыктан,йөрибез хәзер адашып.

**Малай:** Әйдәгез бергә авылга юлны эзлик.

**Әтәчләр:** Әйдә,әйбәт булыр иде юлны табалсак, беркайчан да сугышмас идек, без хәзер бик яхшы беләбез: сугышырга ярамый, дус тату яшәргә!

**( Бергә китәләр)**

**№5 бала**

Дус яшәргә кирәк җир йөзендә,
Дуслар кирәк һәрбер кешегә,
Дуслык булса, яшәү дә күңелле,
Уңай була һәрбер эшең дә.

**№6 бала**

Барыбызга безнең дуслар кирәк,
Дустан башка булмый яшәргә,
Шуңа күрә дөнья буйлап кирәк
Дуслык орлыкларын чәчәргә.
***“Чәчәкләр һәм бал кортлары биюе”***

**Малай:** Бу Бал корты миңа бик тә таныш. Хәерле көн ,кадерле Бал корты! Ә синең исемең ничек?

**Бал корты:** Хәерле көн! Минем исемем Нечкәбил. Мин бик торыш һәм эшчән булдым, бал саклар өчен иң яхшы өй төзедем. Шуның өчен Чәчәкләр патшасы бөтен дөнья чәчәкләреннән безгә бал җыярга рехсәт итте. Ялкау булырга һич ярамый, эшләргә кирәк. Ярар, сау булып торыгыз, минем эшләрем бик күп, закламый кыш килә, эзерләнергә кирәк. (Китә).

**Малай:** Кара инде,юлны сорарга да җитешмәдек.

Малай белән әтәчләр тагын юл буйлап китәләр.

***Сертотмас үрдәк килеп чыга.(Үрдәк булып киенгән бала)***

**Үрдәк:** Бак,бак,бак
Бик авыр йөрүе серне саклап.
Берәрсенә сөйләргәме икән?
Сөйләмичә ничек түзәргә икән.
**Малай:** Исәнме,үрдәк, син нишләп йөрисең урманда?

**Үрдәк:** Исәнме,менә әниең сине эзләргә җибәрде. Мин бит бик ышанычлы үрдәк.Сиңа сөйлисе сүзем бар,малай.Хәзер бер җиргә барып киләм дә, аннары сөйлим. (Китә).

**Малай:** Балалар , бу нинди үрдәк, таныш та түгел?

**Балалар:** Бу Абдулла Алишның Сертотмас үрдәге.

**Малай:** Ә ник ул Сертотмас?

**Алып баручы:**Кил әле утыр, тыңла.

Бик борын заманнарда, башы бүрекле, аягы төкле бер үрдәк булган. Ул үзе, сайрый белмәсә дә, күргән бер кошына, хайванына, ерткычына озак-озак итеп яңа хәбәрләр сөйләргә ярата икән.

Тегеләр аның сүзләрен тыңлый-тыңлый арып бетәләр, я бөтенләй тыңламый ташлап китәләр икән.

Ә менә бердәнбер көнне йорт хуҗасы үзенең этен ияртеп, корыч балтасын биленә кыстырып урманга утын кисәргә дип китергә җыена икән. Хуҗа йорт-җирдәге бар кош-кортларны , хайваннарны җыйган да сузен башлаган.

**Хуҗа:** Мин урманга барам, карагыз аны, өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз! Озак тормам, кайтырмын.

*(Чыгып китә. Кош-кортлар, хайваннар башларын салындырып каралтыларына таралалар, шул вакыт бик аптыраган кыяфәттә ...)*

**Үрдәк:** Һич аңламыйм, нигә берәүгәдә белдермәскә кушты икән?

*(Каралтыга кереп китә)*

**Әби:** Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган. Икенче көн дә җиткән, болар инде хәзер борчыла башлаганнар.

**Күркә:** Бүген дә кайтмас бу, әллә хуҗаны чакырып кайтырга берәрсен җибәрикме урманга.

**Тавык:** Арабыздан кайсыбызны сайлыйк икән?

**Әтәч:** (үрдәккә карап) Син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, гел бакылдап кына торасың, син бар!

**Тавык:** (үрдәккә карап) Ләкин берүк нишләп йөрүеңне берәүгә дә белгертәсе булма!

**Үрдәк:** Ярар, сезнең хакыгыз өчен генә барсам барырмын инде.

*(Каралтыларына кереп китәләр)*

**Әби:** Иртә торгач та үрдәк, уйлап-нитеп тормаган, тамагын туйдырган да, юлга чыккан. Башта ул канатларын кагып очкан, оча-оча бер елгага барып төшкән. Ишкәкләре — тәпиләре үзендә булганга аптырамаган, йөзеп тә киткән. Елга буйлап озак йөзгәч, корыга чыгып, тәпи-тәпи дә йөгергән…

Бара-бара куе бер урманга барып җиткән. Төрле тәмле җиләкләр, симез бөҗәкләр ашый-ашый, урманга кереп тә киткән. Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер керпе килеп чыккан һәм аңа сүз дә кушкан.

**Керпе:** Исәнме, үрдәк, кая барасың болай ашыгып.

**Әби:** Үрдәккә инде шул гына кирәк тә. Юл буе берәү дә очрамаганга, берәү белән дә җәелеп сөйләшергә туры килмәгәнгә, аның бик эче пошкан булган, иптәшләренең әйткәннәрен дә оныткан, сүз артыннан сүзне тезәргә тотынган.

**Үрдәк:** Урманда утын кисүче хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез дә аңа ияреп киткән иде. Хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр.

**Керпе:** Синең өең еракмы соң? Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы?

**Үрдәк:** И, безнең өйдә еланнарның бөтенләй булганы да юк, сарай тирәсендә шул хәтле күп тычкан, хәтта куселәр дә бар. Мыраужан исемле песиебез гел ауда йөри, кайчак җәлләп тә куям инде үзен. Менә шушы сукмак безнең өйгә туп-туры алып бара, беркемгә дә әйтмә, кара!

**Керпе:** Мин инде андый усалларның берсе дә түгел, синең серләреңне белсәм дә, каян килүеңне күрсәм дә, сиңа зарарлы эш эшләмәм. Шулай да син саграк бул. Очраган берәүгә серләреңне сөйләмә. Серең эчендә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр.

**Әби:** Керпенең бу акыллы киңәшенә үрдәк һич колак салмаган, ашыга-ашыга урман эченәрәк атлаган.

Бара-бара үрдәккә озын колаклы бер куян очраган һәм ул да аңардан сораган.

**Куян:** Әй, бүрекле үрдәк, күзгә төсле матур, кыр төсле зур күл булганда, ни эшләп урманда буталып йөрисең?

**Үрдәк:** Хуҗабыз белән этебез урманга утын кисәргә киткәннәр иде, өебез ялгыз калды,  хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр. (Горурланып)

**Куян:** (читкәрәк китеп) Алай булгач, хуҗаның алмагачларын кимерергә барырга бик җайлы вакыт икән. (Үрдәккә карап) Синең өең еракмы соң?

**Үрдәк:** Менә шушы сукмак безнең өйгә туп-туры алып бара, беркемгә дә әйтмә, кара!

**Куян:**  Хуҗаңны күргәнем юк. (Куаклар арасына кереп китә)

**(Үрдәк керә)**

**Үрдәк:** Менә әйләнеп тә килдем.

**Малай:** Көн кичкә авыша, тизрәк кайтырга кирәк. Әнием белән әтием бик кайгырырлардыр. Әйдә син дә безнең белән, үрдәк дус.

**Барлык геройлар чыгалар:**

**Менә нинди мөһим сүзләр ул! Онытмагыз, сез дә, истә тотыгыз!**

**Автор**: Бик авыр юлны сайлаган ул,
Кыю кичкән үлем даласын.
Яшь буыннар өчен маяк ул:
Рухландырыр балам баласын!

***Татарча "Күмәк бию"***

**Йомгаклау**

Еллар узган саен, милли бәйрәмнәр, халкыбызның гореф-гадәтләре,йолалары әкренләп онытыла бара. Шәһәр җирендә генә түгел, авыл җирендәдә бер-берсен белмәүчеләр бар хәзер. Бер-беребез белән аз аралашабыз.Бәйрәм көннәрендә туйганчы җырлашып утырулар бары тик әби-бабаларыбызның хәтерендә генә саклана. Ә кайбер әби-бабаларыбыз борын- гыдан килгән күп кенә бәйрәм күренешләрен хәтерләмиләр дә, чөнки аларның яшьлек еллары милли гореф-гадәтләребезне җимерү, бетерү вакытына туры килгән , ләкин шулай булса да авылларда искиткеч зиһенле әби-бабаларыбыз сирәк булса да бар әле.

Безгә бу әби-бабаларны табып, татар халкының бәйрәмнәрен,йолаларын язып каласы, саклыйсы иде. Алар

кебек пакъ күңелле, юмарт, кунакчыл, олы җанлы булып каласы иде. Ә моның өчен безгә, укучыларга, халкыбызның йола-бәйрәмнәрен торгызу һәм яңарту эшенә өлеш кертергә кирәк.

## Кулланылган әдәбият


1. Гарипова Ф.Г. “Авыллар һәм калалар тарихыннан” Казан. - 1997.

2.”Ватаным Татарстан” газетасы, 4 июль, 2008 ел.

3. Никольский Н.В. “Сборник исторических материалов о народностях Повольжья. - Казань, 1919.

4. Мөхәммәтҗанов Р. Эзләсәң табыла. - Казан утлары. - 1977. - № 9.

5. Маннур Ш. Агымсуларга карап. - Казан, 199

6. Уразманова Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре.

7. Татар мөселман календаре. - Казан. - 1997.

8. Татар мөселман календаре. - Казан. - 1998.

**Эчтәлек**

Кереш. ..........2 бит

1.“ Тукай безнең күңелләрдә”..................................3-8 бит

2."Кызыл ромашка таҗлары" Патриот шагыйрь –

Муса Җәлилгә багышланган кичә..............................................................
..........................................................................9-14 бит

3.“Сөмбелә”бәйрәме................................................15-19 бит

4.«Каурый, каз өмәсе»............................................20-23бит

5. “Сабантуй” бәйрәме.............................................24-28 бит

6.“Нәүрүз – язгы бәйрәм”.........................................29-31бит

7. “Карга боткасы бәйрәме”.......................................32-35бит

8. “Әбиемнең –серле сандыгы”..................................36-41 бит

9. “День родного языка, «Туган тел»!бәйрәме............42-46 бит

10. Абдулла Алиш иҗатына багышланган бәйрәм кичәсе

..............................................................................47-53бит

Йомгаклау..........................................................54 бит

Кулланылган әдәбият................................................55 бит

Эчтәлек...........................................................56 бит